ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «07» октябреннән № 401

**«2017 елга Яңа Чишмә муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында»**

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

2017 нче елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын;

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына:

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар ташу өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында расланган бәя нормативлары нигезендәтәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «07» октябрендәге
404 номерлы карары белән
расланган

2017 нче елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасы узышының бер километрына ставка, елга сум |
| КАВЗ | 103980 | 33,53 |
| ПАЗ | 104238 | 33,52 |
| ГАЗ «Газель» | 98836 | 28,22 |
| УАЗ | 98383 | 27,10 |
| FIAT | 98125 | 26,10 |
| Peugeot Boxer | 98640 | 25,73 |
| Ford Transit | 99464 | 28,11 |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «07» октябрендәге
404 номерлы карары белән
расланган

# Нигезләмә
# Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар ташу өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативларын исәпләү тәртибе турында

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе нормативлары ел саен Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган, автотранспорт чарасың хисап елында фактта узган юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. I-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - m моделле автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы, километр ;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән ташуны оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына, бәя нормативы ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.